Татарстан Республикасы Хисап палатасы

Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2018 елда эше турында ХИСАП

Казан – 2019 ел

Эчтәлек

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге .....…….....3

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге .....……....18

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары, тышкы финанс тикшерүенең региональ органнары Европа оешмасы белән үзара хезмәттәшлек итү.....……...42

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы белән үзара хезмәттәшлек итү.....…….…….47

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек итү .....……...49

Эшчәнлектәге хәбәрдарлык …….....52

Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2018 елда эше турында Хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эше турында Хисап 2004 елның 7 июнендә кул куелган 37-ЗРТ номерлы «Татарстан Республики Хисап палатасы турындагы» Законның 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта закон тарафыннан билгеләнгән максат һәм вәкаләтләрне башкару буенча Хисап палатасының 2018 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

2018 елда Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды (алга таба – Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды) бюджетын формалаштыру һәм үтәүне тикшерү кысаларында:

- **Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертизалар** (йомгаклары буенча 24 бәяләмә әзерләнде);

- «2019-2021елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызга үз теләкләре буенча Татарстан Республикасына күчеп кайтырга ярдәм итү» **дәүләт программасы проектына экспертиза;**

- Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында **еллык хисапны тышкы тикшерү** һәм 2017 ел өчен бюджет чараларын төп кулланучыларның **бюджет хисапларын тышкы тикшерүләр** (39 бәяләмә)**;**

- 2017 ел өчен **Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү;**
- 2018 елның 1 кварталында, 1 ярты еллыгында һәм 9 ае өчен **Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше мониторинглары** (6 бәяләмә) уздырылды.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 157 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 47.1, 64 маддәләре нигезендә хисап елында **«2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында»** законы проектына экспертиза үткәрелде.

Хисап палатасы бәяләмәсендә бюджет проектының республика Министрлар Кабинеты резерв фонды зурлыгы, бюджет кытлыгы, дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтүгә чыгымнар өлешендә бюджет законнары белән билгеләнгән чикләрне исәптә тотып формалашуы билгеләп үтелә.

2019-2021 елларга республика бюджеты проекты балансланган. Кытлыкны финанслауның төп чыганагы булып бюджет чараларын исәпкә алу буенча исәпләрдә калган чаралар тора, бу республика бюджетының финанс тотрыклылыгы өчен шартлар тудыра.

2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар планлы вакыт аралыгына республика бюджеты проектын эшләгәндә нигез итеп алынган төп макроикътисадый күрсәткечләр фаразы Россия Федерациясе икътисады үсеше сценар шартларының «база» вариантын истә тотып төзелгән. Төзелеше һәм эчтәлеге буенча

2019-2021 елларга социаль-икътисадый үсеш фаразы стратегик планлаштыру турында законнар таләпләренә туры килә.

Стратегик планлаштыру документларының үзара килешүен тәэмин итү максатында Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр Социаль- икътисадый үсеше стратегиясенең индикаторларын, шулай ук, икътисадый хәлдән һәм Россия Президентының «2024 елга кадәр Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» Указында билгеләнгән бурычлардан чыгып, Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр Озак вакытка исәпләнгән фаразы һәм республика дәүләт программалары күрсәткечләрен тәгаенләргә тәкъдим ителде.

Бәяләмәдә 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр килү фаразы бюджет проектын кертү датасына республиканың гамәлдәге законнары нигезендә эшләнүе билгеләп үтелә. Федераль дәрәҗәдә 2019 елдан планлаштырыла торган салым һәм бюджет законнарында үзгәрешләр Россия Федерациясе субъектлары керемнәре мәсьәләләренә тәэсир итә. Төп үзгәреш каты алкогольгә акцизлар язып кую нормативларына кагыла. Әлеге шартларда федераль актлар кабул иткәннән соң Татарстан Республикасы бюджетының беренче укылышта расларга тәкъдим ителгән параметрларын тәгаенлау зарурлыгы килеп чыгарга мөмкин.

Республика бюджеты проекты федераль бюджет проектын Россия Федерациясе Дәүләт Думасына кертүгә кадәр тәкъдим ителде. Шуңа бәйле рәвештә кайбер трансфертлар буенча закон проектында 2019 елга күрсәткечләр федераль бюджет проектында республика өчен каралган күләмнәргә туры килми.

Республика бюджетының чыгым өлешендә социаль әһәмияткә ия чыгымнар 2019 елга чыгымнарның гомуми күләменә карата 72% тәшкил итә.

2019 елга республиканың ачык норматив йөкләмәләрен үтәүгә чыгымнар гамәлдәге норматив хокукый актларны һәм инфляциянең фаразлана торган дәрәҗәсен исәптә тотып билгеләнгән.

2019 ел бюджетының программа өлеше бюджет чыгымнарының гомуми өлешенең 88,8 процентын тәшкил итә һәм республиканың 29 дәүләт программасын тормышка ашыруга ассигнованиеләрне үз эченә ала.

Аерым дәүләт программалары буенча экспертиза кысаларында бюджет проектында каралган һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларында раслланган финанслау күләмнәренең туры килмәве билгеләп үтелә.

2019 елга һәм планлы вакыт аралыгына бюджет проектында федераль бюджеттан субсидияләр хисабына спорт инфраструкктурасын булдыру өчен спорт-технология җиһазлары сатып алуга чыгымнар карала. Хисап палатасы бәяләмәсендә чыгым өлешенә республика бюджеты чаралары хисабына күрсәтелгән максатларга ассигнованиеләр кертүнең федераль бюджеттан чаралар алу өчен нигез булдыруы билгеләп үтелә.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 145 маддәсе һәм Татарстан Республикасы бюджет кодексының 47.1 маддәсе нигезләмәләре буенча хисап елында Татарстан Республикасы **«2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар планлы вакыт**

аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе Территориаль фонды бюджеты турында» законы проектына экспертиза уздырылды.

Бәяләмәдә Закон проектының бюджет законнары таләпләрен исәптә тотып формалаштырылуы билгеләп үтелә. Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты проекты балансны – керемнәр һәм кытлыкны финанслау чыганакларыннан кертемнәр күләме планлаштырыла торган чыгымнар күләменә туры килә. Кытлыкны финанслау чыганаклары булып бюджет счетларында калган чаралар билгеләнүеннән чыгып, ММИ Территориаль фонды бюджеты балансылыгы 2018 ел бюджеты үтәлешенә бәйле булачак.

Хисап палатасы закон проектында Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының керемнәренең аерым кодларының 2019 елдан башлап куллана торган Россия федерациясе бюджет классификациясенә туры килмәвен билгели. Тиешле үзгәрешләр төзәтмәләр рәвешендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проектын икенче укылышка кертелде.

Хисап вакыт аралыгында «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» законының 4 проектына һәм «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» законының 2 проектына экспертиза уздырылды. Кертелгән төзәтмәләр белән

керемнәр буенча күрсәткечләр, чынбарлыктагы кертемнәрне исәпкә алып, чыгым өлешендә тиешле чагылыш табып тәгаенләнде.

Республика бюджеты күрсәткечләренә төзәтмәләр кертү барышында бюджет законнары белән билгеләнгән чикләүләр һәм таләпләр сакланган.

2018 елда Хисап палатасы түбәндәге экспертизаларны уздырды:

1. Салым һәм бюджет законнары мәсьәләләренә кагыла торган **Татарстан Республикасы законнарының 14 проектына.** Экспертизалар барышында закон проекты нигезләмәләренең, тәкъдим ителгән редакциядә кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетына кертемнәр күләменә, республика бюджеты баланслылыгына тәэсире, шулай ук закон проектларының бюджет законнары таләпләренә туры килү мәсьәләләре каралды.

Хисап палатасына экспертизага кертелгән закон проектларына Бәяләмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына билгеләнгән вакытларда тәкъдим ителде һәм профильле комитетлар утырышларында каралды.

Татарстан Республикасының түбәндәге законнар проектларына экспертиза уздырылды:

- «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзелеше белән бәйле булган торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген дәүләт тикшерүе (күзәтчелеген) тормышка ашыру буенча Татарстан

Республикасы вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законының 1 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында»;

- «2019 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында»;

- «Оешмалар милкенә салым турында» (өч закон проекты);

- «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» (өч закон проекты);

- «Татарстан Республикасы күппрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә төзелгән алдынгы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында»;

- «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турында килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау турында»;

- «Татарстан Республикасының «Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана торган салым түләүчеләр өчен дифференцияләнгән салым ставкалары билгеләү турында» Законының 2 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында»;

- «Татарстан Республикасының «Транспорт салымы турында» Законының 6 маддәсе1 подпунктын гамәлдән чыккан дип исәпләргә».

Хисап елында шулай ук Татарстан Республикасының «Мәгариф турында» законы нормаларын үтәү кысаларында кабул ителә торган Татарстан Республикасы «2019 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм

һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм бушлай мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп, гомуми урта белем алуга, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итүнең нормативларын раслау турында» һәм «2019 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә һәркем алырлык һәм бушлай мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итүнең нормативларын раслау турында» законнары проектларына экспертиза уздырылды.

Экспертиза йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына гомуми белем бирү өлкәсендә эшчәнлекне тормышка ашыра торган һөнәри белем бирү оешмалары өчен норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен раслау тәкъдиме белән хат юлланды. Республика Хөкүмәте Хисап палатасы тәкъдимен исәпкә алды, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 8 августында кул куелган 566 номерлы «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслау турында» карарына тиешле үзгәрешләр кертелде.

2. Татарстан Республикасының **«2017 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»** һәм «**Татарстан Республикасы бюджеты Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетының үтәлеше турында**» законнары проектлары.

Экспертиза йомгаклары буенча законнар проектлары күрсәткечләренең Хисап палатасының тышкы тикшерүен узган

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисап күрсәткечләренә туры килүе расланды. Төзелеше һәм эчтәлеге буенча законнар проектлары һәм аларга кушымталар бюджет законнарында билгеләнгән таләпләрне саклап формалаштырылганнар.

3. **«2019-2021 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызга үз теләкләре буенча Татарстан Республикасына күчеп кайтуга ярдәм итү»** Татарстан Республикасы дәүләт программасы проектына.

Хисап палатасы бәяләмәсендә программа проектында бюджеттан тәкъдим ителә торган күләмнәрдә финанслау ихтыяҗын нигезләү барлыгы, әмма программа чараларын тормышка ашыру өчен бюджеттан тыш чараларны һәм муниципаль берәмлекләр бюджеты чараларын җәлеп итү мөмкинлеге яисә мөмкин булмавы турында мәгълүмат юклыгы билгеләп үтелә.

Дәүләт программасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланды.

Хисап палатасына законнар белән йөкләнгән бурычлар һәм вәкаләтләр нигезендә хисап елында **2018 елның 1 кварталында, 1 яртыеллыгында һәм 9 ае эчендә** мониторинглар үткәрелде һәм **Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының үтәлеше турында** тиешле бәяләмәләр әзерләнде.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының үтәлеше турында бәяләмәләрдә салым һәм салым булмаган керемнәр, кире кайтарылмый торган максатчан чараларның керүенә, чыгым йөкләмәләре үтәлешенә, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларыннан җәлеп ителгән чаралар күләменә, алдагы елның шундый ук күрсәткечләре белән чагыштырмада бюджетлар үтәлешенең төп күрсәткечләре динамикасына, бюджет турында законнарының текст маддәләре үтәлешенә анализ нәтиҗәләре чагылыш тапты.

Татарстан Республикасы бюджетының агымдагы үтәлешен тикшерү йомгаклары буенча, чынбарлыктагы үтәлешне исәпкә алып, 2018 елга Бюджет турында Законның 8 маддәсендә билгеләнгән Татарстан Республикасы ачык норматив йөкләмәләр үтәлешенә чыгымнар күрсәткечен тәгаенләргә тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының үтәлеше мониторингы йомгаклары буенча, авиация кулланып, медицина ярдәме күрсәтү өчен Р сатып алуга бюджет ассигнованиеләрен чагылдыруның билгеләнгән тәртиптә үтәү максатында 2018 елга Фонд бюджеты турындагы законга үзгәрешләр кертү кирәклеге билгеләп үтелә.

Бюджет турында тиешле законнарга үзгәрешләр керткәндә Хисап палатасы тәкъдимнәре исәпкә алынды.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Бәяләмәләр квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителде.

Россия Федерациясе Бюджетының 149, 264.4 маддәләренең һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97.3, 97.6 маддәләренең нигезләмәләрен тормышка ашырып, хисап елында **2017 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тикшерү турында Хисапны тышкы яктан тикшерү һәм 2017 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының үтәлеше турында Хисапны тикшерү** уздырылды.

2017 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында еллык хисап һәм аның белән бергә бирелә торган документларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тышкы яктан тикшерү үткәрү өчен үз вакытында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97.4 маддәсендә билгеләнгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Хисап палатасына җибәрде.

Бюджет законнары нигезендә хисап елында 2017 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапка тышкы яктан тикшерү бюджет чараларының төп кулланучыларының, бюджет керемнәренең төп администраторларының, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторларының еллык бюджет хисаплылыгын тикшерүне үз эченә алды.

Төп администраторларның еллык бюджет хисабы 2010 елның 28 декабрендә кул куелган Россия Федерациясе Финанслар министрлыгының 191н номерлы боерыгы белән расланган Еллык, квартал һәм айлык хисапларны төзү һәм бирү тәртибе турында инструкциясе таләпләрен истә тотып төзелгән

һәм 2017 елга билгеләнгән бюджет классификациясе кодлары буенча формалаштырылган.

Керемнәр, чыгымнар күләме һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча 2017 ел өчен Татарстан Республикасы бюджет үтәлеше турында Хисап күрсәткечләренең бюджет чараларының төп администраторларының еллык бюджет хисабының җыелма күрсәткечләре һәм 2018 елның 1 гыйнваренә карата торышы буенча Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписе күрсәткечләре белән туры килә.

2017 елда республика бюджеты керемнәре – 244 267,7 млн. сум, чыгымнары – 231 088,5 млн. сум, бюджет профициты 13 179,2 млн. сум тәшкил итте.

2017 ел өчен бюджет үтәлеше турында Хисап күрсәткечләренең законнар белән расланган билгеләнешләрдән тайпылу нигезләре һәм сәбәпләре бюджет законнары белән билгеләнгән исемлеккә туры килә.

Расланган күрсәткечләр салым керемнәре буенча – 3,3 % ка, салым булмаган керемнәр буенча – 1,9% ка, кире кайтарылмый торган кертемнәр буенча 6,4 %ка үсеш белән үтәлде.

Программа чыгымнары 222 131,3 млн. сум, ягъни расланган билгеләнешләрнең 98,7% тәшкил итте.

18 дәүләт программасын тормышка ашыруга чыгымнар расланган билгеләнешләрдән түбәнрәк күләмдә башкарылды, бу, гомумән алганда, дәүләт заказын урнаштырганда конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча чараларны янга калдыру, хезмәтләр башкаруга дәүләт контрактларын соңга калып төзү белән бәйле. Татарстан Республикасы Дәүләт программалары

һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибендә билгеләнгән якын килү буенча 3 дәүләт прораммасы (программа чыгымнарының гомуми күләменнән 0,01%) 2017 елда нәтиҗәлелекнең канәгатьләнмәслек дәрәҗәсендә тормышка ашырылган.

Ачык норматив йөкләмәләрне тормышка ашыруга чыгымнар 16 116,2 млн. сум тәшкил итте. Республиканың 2017 ел азагына ачык норматив йөкләмәләр буенча кредит бурычлылыгы юк.

2017 елда дебиторлык һәм кредит бурычлылыгы күләмнәрен киметү буенча уңай динамика күзәтелә. Ел азагына дебиторлык бурычлылыгы – 15 335,4 млн. сум, кредит бурычлылыгы 247,4 млн. сум тәшкил итте.

Бюджет чараларын төп кулланучыларның хисаплары буенча вакыты кичерелгән кредит бурычлылыгы юк. Чыгым йөкләмәләре бюджет чараларын төп кулланучылар тарафыннан җиткерелгән лимитлар чикләрендә кабул ителгән.

2017 елда республика бюджетын үтәгәндә республика Министрлар Кабинеты резерв фонды, бюджет кытлыгы, дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтүгә чыгымнар зурлыгы буенча бюджет законнары белән билгеләнгән чикләүләрне саклау тәэмин ителде.

2017 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында хисапны тикшерү йомгаклары буенча хисапта чагылыш тапкан керемнәр буенча – 41 378,6 млн. сум, чыгымнар буенча – 41 505,7 млн. сум, бюджет кытлыгы 127,1 млн. сум күләмендәге күрсәткечләр расланды.

2017 ел өчен Татарстан Республикасы бюджетының үтәлеше турында Хисапка Бәяләмә – Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, 2017 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында хисапка Бәяләмә – Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителде.

2011 елның 7 февралендә кул куелган 6-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнарын оештыру һәм эшчәнлегенең төп принциплары турында» Федераль законы буенча Хисап палатасының эшчәнлеге тышкы дәүләт финанс тикшерүе стандартлары нигезендә тормышка ашырыла. .

Хисап елында гамәлдәге стандартларны актуальләштерү буенча эш дәвам итте.

Тышкы финанс тикшерүен тормышка ашыру вакытында муниципаль тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлек иткәндә бердәм якын килүләрне ачыклау максатларында «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары белән берлектә яки параллель тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары үткәрү» Тышкы финанс тикшерүе стандарты эшләнде.

Стандартны эшләгәндә норматив хокукый база, Татарстан Республикасы Хисап палатасының әлеге юнәлеш буенча эш тәҗрибәсе, «Бергә һәм параллель тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары үткәрү тәртибе» Тышкы дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе типовой стандарты (Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы ТХО Советы

Президиумы карары белән расланган) һәм «Россия Федерациясе Хисап палатасының Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары белән берлектә яки параллель тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары үткәрү» стандарты нигезләмәләре исәпкә алынды.

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

2018 елда Хисап палатасы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы министрлыкларында, ведомство, учреждениеләр һәм оешмаларында, шулай ук 11 муниципаль районда тикшерү чаралары уздырды.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов йөкләмәсе буенча шактый тикшерү чарасы: 2017 елда республика һәм муниципаль китапханәләрне китап фондларын комплектлаштыру өчен кирәк булган Татарстан Республикасы бюджеты чараларына ихтыяҗ булуны исәпләүнең нигезле булуын тикшерү; продукция һәм технологияләрнең яңа төрләрен җитештерүне үзләштерү һәм ярдәм күрсәтү инфраструктурасы объектлары («Химград» технополисы» югары технологияләр өлкәсендә технопарк, «Идея» Инновацияле-җитештерү Технопаркы, «Мастер» Кама индустриаль паркы, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк) эшчәнлеген оештыруның нәтиҗәлелеген тикшерү уздырылды. «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопаркында үткәрелгән тикшерү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 26 маенда кул куелган 352 номерлы карары белән расланган «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә кече эшмәкәрлек субъектларын бизнесинкубаторлаштыру» Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 августында кул куелган 721 номерлы карары белән үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча инвалидларны һәм инвалид балаларны тернәкләндерү белән бәйле мәсьәләләр буенча бюджет чараларын тотуга

нәтиҗәлелек аудиты, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә парклар һәм скверлар булдыру һәм төзекләндерүгә республика бюджеты чараларын куллануны тикшерү уздырылды.

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе белән берлектә Хисап палатасы инспекторлары (эксперт группасы составында) республика Мәдәният министрлыгы карамагындагы учреждениеләрдә («Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» ДБУ, « В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» МДБУ, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Буа дәүләт драма театры, Г.Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры); «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисадый эзләнүләр үзәге» ДБУдә, шулай ук Бөгелмә, Алабуга һәм Яңа Чишмә муниципаль районнарында коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыруда гамәли ярдәм күрсәтү буенча комплекслы чаралар уздыруда катнаштылар.

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы мөрәҗәгате буенча гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм саклау буенча чаралар уздыруга акча чараларын куллануны тикшерү уздырды (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы).

Татар транспорт прокуратурасы мөрәҗәгате буенча бюджет законнары үтәлүне, шул исәптән диңгез һәм эчке су транспортын үстерүгә бүлеп бирелгән субсидияләр, бюджетара

трансфертлар, башка ассигнованиеләрне үзләштерүне тикшерү уздырылды.

Хисап палатасы Татарстан Республикасында Террорга каршы тору комиссиясенең эксперт группасы составында Әлки, Яшел Үзән, Лаеш һәм Саба муниципаль районнарында террорга каршы тору комиссияләрен тикшерүдә катнашты.

Уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча **гомуми күләме 3 420,6 млн. сум булган бозулар,** шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты чаралары буенча – 1 974,7 млн. сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары – 1 207,2 млн. сум, финанслаштыру чаралары буенча – 97 млн. сум, башка чаралар 141,7 млн. сум **ачыкланды**.

Комплекслы һәм тематик тикшерүләр уздыру вакытында түбәндәге бозулар ачыкланды:

- дәүләт (муниципаль) милке белән идарә итү һәм аннан файдалану өлкәсендә бозулар – 2 367,0 млн. сум;
- бухгалтерлык (бюджет) исәбен алып бару һәм хисаплылыкны бозулар– 776,7 млн. сум;
- бюджетны формалаштыру һәм үтәү вакытында бозулар – 127,9 млн. сум;
- дәүләт (муниципаль) сатып алуларны тормышка ашыру вакытында бозулар – 99,2 млн. сум;
- бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану – 49,1 млн. сум;
- бюджет чараларын максатсыз файдалану – 0,086 млн. сум;
- башка төр бозулар (субсидия алучыларның хисап бирмәүләре, бюджет законнарын башка бозулар) – 0,651 млн. сум.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан 2018 ел эчендә уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча ачыкланган финанс бозуларының төзелеше

млн. сумнарда



Ачыкланган бозуларның иң зур күләмдәге суммалары дәүләт һәм муниципаль милекне куллану, теркәү, исәпкә алу һәм файдалану, бухгалтерлык исәп-хисабын алып бару һәм хисаплар төзү тәртибе, бюджетларны формалаштыру һәм үтәү белән бәйле.

Ел дәвамында аерым тикшерү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профильле комитетлары утырышларында каралды.

2018 елның февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт буенча комитет утырышында депутатлар Хисап палатасының 2017 елда республика парламенты йөкләмәсе буенча уздырылган **2015-2017 елларда**

медицина учреждениеләрен һәм гражданнарның аерым категорияләрен дару чаралары, медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалануны тикшерү нәтиҗәләре турында хисабын тыңладылар һәм аның буенча фикер алыштылар.

2017 елда дару чаралары, медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр белән бушлай тәэмин итүгә хокукы булган затларның саны 17 563 кә кимеде, бу региональ регистрны актуальләштерү белән бәйле. Дару чаралары белән бушлай тәэмин итүгә хокукы булган затларның гомуми саны 324 448 тәшкил итте. 2015-2016 елларда «Таттехмедфарм» ДУП Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән төзелгән контрактларда каралган күләмнәрдән 53 млн. сумга артык дәвалау препаратлары белән тәэмин итте. Шулай итеп, министрлыкның кредит бурычын арттыруга китерә торган лимиттан артык йөкләмәләр барлыкка килү куркынычы туды.

Моннан тыш, аерым очракларда предприятиеләргә республика медицина учреждениеләре хаҗәтләре өчен файдалану вакыты бик аз гына калган дару чаралары, медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр сатып алу тормышка ашырылды. Җитмәсә, алынган препаратларның 21 млн. сумлык бер өлеше – кулланылмаган һәм куллану вакыты чыгу сәбәпле хисаптан төшерелгән. Комитет Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына «Таттехмедфарм» ДУП белән берлектә дару чаралары, медицина билгеләнешендәге эшләнмәләрне сатып алуны федераль законнар буенча контракт нигезендә эшләргә, дару чаралары, медицина билгеләнешендәге

эшләнмәләрнең калган санын киметү максатлары белән тәэмин итүчеләрдәге шундый ук продукциягә бәяләрне анализлау уздырырга, аларны сатып алуны аларга ихтыяҗны исәптә тотып оештырырга тәкъдим итте.

2018 елның ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук саклау буенча комитеты утырышында Хисап палатасы уздырган **мәгариф һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын саклау буенча комиссияләр эшчәнлеген оештыру буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалануны тикшерү** нәтиҗәләре турында хисап тыңланды.

Тикшерү барышында 85,9 мең сум күләмендәге Татарстан Республикасы бюджеты чараларының максатсыз файдаланылуы ачыкланды. Ачыкланган бозулар буенча бюджет чараларын максатсыз файдаланырга мөмкинлек бирелгән учреждениеләр, шулай ук аларның җитәкчеләре һәм баш хисапчыларына карата административ беркетмәләр төзелде. Тикшерү нәтиҗәләре буенча республика Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы бюджет чараларын максатсыз файдалану фактлары буенча бюджет чараларын мәҗбүр итеп куллану турында хәбәр итү юлланды.

2018 елның декабрендә Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча Комитеты утырышында республикада парклар һәм скверларны булдыру һәм төзекләндерүгә Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалану буенча тикшерү нәтиҗәләре каралды.

Тикшерү чарасы Татарстан Республикасы Парламенты йөкләмәсе буенча республика муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары белән берлектә уздырылды. Парклар һәм скверларны булдыру һәм төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруга 2016-2018 елларда 6 600,3 млн. сум, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты чаралары – 4 855,5 млн. сум, федераль бюджет чаралары – 1 744,8 млн. сум каралган. Өч ел эчендә 169 җәмәгать урыны (пространствосы) төзекләндерелде, шул исәптән 52 объектка капиталь ремонт үткәрелде, 18-е реконструкцияләнде, 99 яңа парк һәм сквер төзелде. Бухгалтерлык исәп-хисабын алып бару һәм башкарылган хезмәтләрне документаль рәсмиләштерү өлешендә ачыкланган аерым бозулар юкка чыгарылды. Башкарылган хезмәтләрнең билгеләп үтелгән техник кимчелекләре гарантия йөкләмәләре кысаларында юкка чыгарылалар.

2018 елда Татарстан Республикасы Хисаап палатасы 492 объектны үз эченә алган **55 тикшерү-ревизия чарасы,** шул исәптән Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенә фундаменталь тикшеренүләр уздыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануга нәтиҗәлелек аудиты һәм инвалидларны һәм инвалид балаларны тернәкләндерү буенча хезмәтләр күрсәтә торган оешмалар эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануга нәтиҗәлелек аудиты уздырды.

2014-2016 елларда һәм 2017 елның узган вакыт аралыгында республика Фәннәр академиясенә гамәли фәнни тикшеренүләр үткәрү өчен бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит барышында 2014-2017 елларга Фәннәр академиясенә еллык Дәүләт бурычларына анализ ясалды, ул Фәннәр академиясенең еллык эш планнарын формалаштыру өчен нигез булып торган Татарстан Республикасында фән, технологияләр һәм техниканы үстерүнең өстенлекле юнәлешләре исемлеген (Татарстан Министрлар Кабинеты тарафыннан 2012 елның 8 ноябрендә кул куелган 2006-р номерлы карары белән расланган) актуальләштерү кирәклекне күрсәтте.

Хисап палатасы тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән буенча совет утырышында тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 ноябрендә кул куелган 2957-р номерлы карары белән актуальләштерелгән Фән, технологияләр һәм техниканы үстерүнең өстенлекле юнәлешләре исемлеге расланды.

Аудит барышында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе башкара торган аерым хезмәтләрнең бәясен билгеләргә мөмкинлек бирә торган эшләнгән нормативларның булмавын ачыкланды.

Шулай ук республика бюджеты чараларыннан, дәүләт милкеннән файдаланганда, дәүләт хаҗәтләре өчен хезмәтләр күрсәтү, эшләр башкару, товарлар белән тәэмин итүгә заказларны үтәгән вакытта Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан җибәрелгән аерым бозулар ачыкланды.

Китап макеты эшләү һәм археологик конгресс уздыру буенча килешүләр бәясенә нигезләнмәгән өстәмә бәягә салым суммасын кертү нәтиҗәсендә Академия 1,1 млн. сум күләмендә артык акча чаралары тоткан.

2014 елда Академия алга таба кулланылмаган гамәлдәге Татарстан Республикасы Ягулык-энергетика комплексын үстерү программасын актуальләштерү буенча Идел буе федераль университеты башкарган эшләргә түләү өчен 0,9 млн. сум тоткан.

Дәүләт милке белән идарә итү һәм аннан файдалану өлкәсендә ачыкланган бозуларның гомуми күләме 4,5 млн. сум тәшкил итә. Тикшерү вакыты аралыгында Ислам тикшеренүләре үзәге тарафыннан бәясе 0,2 млн. сум булган видеоконференц-система файдаланылмаган. Академия складында 0,1 млн.сумлык хаҗәте булмаган алдагы елларда чыгарылган фәнни әдәбият булуы ачыклана.

А.Х. Халиков исемендәге Археология институты тарафыннан Болгар шәһәрендәге баланс бәясе 0,7 млн. сум булган файдаланылмый торган торак йорт бинасын хуҗалык әйләнешенә кертү буенча чаралар күрелмәгән.

А.Х. Халиков исемендәге Археология институты һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гомуми бәясе 1,6 млн. сум булган файдаланылмый торган 4 берәмлек автотранспортны эксплуатациягә тапшыру яисә үз вакытында гамәлдән чыгару буенча чаралар күрмәгән.

Дәүләт сатып алуларын тормышка ашыру вакытында аерым бозулар җибәрелгән. Шулай, «ПК «Астер» ҖЧҖ һәм «ПК «Издат-Принт» ҖЧҖ «Татарстан Республикасы тарихи атласы» һәм «Болгар шәһәре һәм Татарстанда һәм Кырымда татар мәдәниятен өйрәнү» китапларын бастыруга гомуми бәясе

2,5 млн. сум булган ике килешү шартларын бозганнар. Төзелгән килешүләр буенча китапларны әзерләү вакыты – 2016 ел, чынбарлыкта китаплар тикшерү барышында гына китерелгән.

Шулай ук «Легенда-фильм» ҖЧҖ бәясе 0,39 млн.сум булган видеороликлар әзерләүне башкарылган хезмәтләр күләме өлешендә (видео-материалның күләме киметелгән) килешү шартларын бозып тормышка ашыра.

Нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары турында хисап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы шулай ук **инвалидлар һәм инвалид балаларны тернәкләндерү буенча хезмәт күрсәтә торган оешмалар эшчәнлеген тәэмин итүгә 2015-2017 елларда һәм 2018 елның узган вакыт аралыгында бүленеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә карата аудит** үткәрде. Татарстан Республикасында 19 тернәкләндерү үзәген, шул исәптән мөмкинлекләре чикле булган балалар һәм яшүсмерләр өчен 12 үзәк, олылар өчен 7 тернәкләндерү үзәген үз эченә алган дәүләт тернәкләндерү учреждениеләре (2018 елның 1 гыйнваренә карата торыш буенча) челтәре булдырылды.

Татарстан Республикасында 2018 елның 1 ноябренә торыш буенча инвалидларның гомуми саны – 299 179 кеше, шул исәптән: олылар – 284 148 кеше, балалар һәм яшүсмерләр 15 031 кеше тәшкил итә.

Мөмкинлекләре чикле булган балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре Татарстан Республикасының 8 муниципаль районында һәм Казан шәһәрендә (3 учреждение) һәм Яр Чаллы шәһәрендә, олылар өчен тернәкләндерү үзәкләре – 4 муниципаль районда һәм Казан шәһәрендә (2 учреждение) һәм Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан.

Учреждениеләрнең республика территориясендә тигез урнашмавы билгеләп үтелә, бу исә республика муниципаль районнарының күпчелегендә яши торган гражданнар өчен тернәкләндерү буенча хезмәт күрсәтүләр алуның мөмкин булуына йогынты ясый.

Тикшерелә торган вакыт аралыгы эчендә учреждениеләрне финанслауның күләме 1 479,1 млн. сум тәшкил итте.

Тернәкләндерү үзәкләрен тикшерү товарлар һүм хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрне билгеләнгән йөкләмәләрдән артык күләмдә аванслау фактларын билгеләде, бу озак вакытлы дебиторлык бурычлылыгына китерә, ә ул исә бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану куркынычы тудыра.

Кайбер учреждениеләрдә гражданнарны тернәкләндерү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган техник чаралар (махсуслаштырылган җиһазлар) белән тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителмәү билгеләп үтелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендә кул куелган 1101 номерлы карары белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтү тәртибендә кресло-коляскаларда йөри торган инвалид балаларны тернәкләндерү үзәкләренә алып килү буенча транспорт хезмәте күрсәтү каралган. Тикшерүләр барышында мөмкинлекләре чикле булган балалар һәм яшүсмерләр өчен 12 учреждениенең бары тик бишендә генә кресло-коляскаларда йөри торган инвалид балаларны тернәкләндерү үзәкләренә алып килү өчен махсуслаштырылган транспортның булуы ачыкланды.

2014-2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасының «Уңайлы мохит» подпрограммасы чараларын тормышка ашыру

шартларында инвалидларны, мәсәлән, күрү сәләте бозылган инвалидларны, тернәкләндерү буенча хезмәт күрсәтә торган учреждениеләрнең кайберләрендә (Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай шәһәрләре) сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикле булган гражданнарның ихтыяҗын канәгатьләндерә торган тирәлек оештырылмау билгеләп үтелә.

Стационар шартларда тернәкләндерү буенча хезмәтләр ала торган инвалидларны тукландыру продуктларының аерым төрләре буенча нормалар сакланмау фактлары ачыкланды.

Тернәкләндерү үзәкләре хезмәтләрен алучылар арасында уздырылган сораштыру хезмәт күрсәтү шартлары белән (85%), тернәкләндерү чараларының сыйфаты һәм исемлеге белән (91%) канәгатьләнүнең югары дәрәҗәсен күрсәтте.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Татарстан Республикасында **җирләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны, гомуми таралган файдалы казылмаларны чыгару вакытында закон таләпләрн саклауны тикшерү** уздырды.

2015-2017 еллар эчендә Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджетына гомуми таралган файдалы казылмалар чыгару белән бәйле түләүләр 220,8 млн. сум тәшкил итте, өч ел эчендә әлеге кертемнәрнең үсеше 6,2% – 2015 елда 71,1 млн. сумнан 2017 елда 75,6 млн. сумга кадәр тәшкил итте.

Тикшерү барышында кирәкле документларны рәсмиләштермичә һәм алардан файдаланган өчен түләмичә генә муниципаль җирләрдә урнашкан санкцияләнмәгән карьерлардан әллә нигә бер файдалану фактлары ачыкланды.

Әлеге юнәлеш буенча башка вәкаләтле органнарның эшчәнлегенә анализ ясалды. Тулаем алганда вәкаләтле дәүләт органнары ачыклаган бозуларның күләме ел саен кими.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы 2016 ел эчендә гомуми таралган файдалы казылмаларны лицензиясез чыгаруның – 121, 2017 елда – 93, 2018 елда 67 очрагын ачыклый. Шул ук вакытта лицензияле шартларны бозуларның ел саен артуы күзәтелә: 2016 елда – 72, 2017 елда – 154, 2018 елда – 250.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы 2016-2018 елларда җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә 14 җинаятьне ачыклый.

Подрядчы оешмаларның дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен юл эшләрен башкаруның чикләнгән вакыты шартларында җирле руда булмаган материаллардан файдалану, кирәкле документацияне рәсмиләштерү вакытында проблемалар һәм, нәтиҗә буларак, штраф санкцияләре белән очрашуларын билгеләп үтәргә кирәк.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановка Юл эшләре башкару вакытында җирле руда булмаган материаллардан файдалану процедураларын гадиләштерү, муниципаль җир тикшерүенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм башка юнәлешләр буенча тәкъдимнәр белән тикшерү чарасы нәтиҗәләре турында хисап юлланды.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында уздырылган 2016-2017 елларда **Азнакай, Арча, Балтач, Кайбыч, Кукмара муниципаль районнарының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын файдалануны тикшерү** нәтиҗәләре буенча аерым вазыйфаи затларның субсидияләр бирү өчен нигез булып торган документларга дөрес булмаган мәгълүматлар кертү фактлары билгеләнә.

Мәсәлән, Арча муниципаль районы фермерына сөт юнәлешендәге мини-ферма төзелешенә чыгымнарның бер өлешен каплауга 0,2 млн. сум күләмендә субсидия биргәндә составына күрсәтелгән районның вазыйфаи затлары кергән комиссия мини-ферманың төзелеш әзерлеге турында бәяләмә бирелә. Урынга чыгып тикшерү барышында мини-ферманың чынбарлыкта төзелмәве ачыклана – нигез, стеналар, түбә, идәннәр, тәрәзәләр, ишекләр һәм бизәү эшләре булмый.

Моңардан тыш, авыл җирлеге башлыклары Татарстан Республикасы район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә субсидия алу өчен гражданнарда санала торган терлек саны турында ялган мәгълүматлар булган белешмә-исәпләүләр тапшыра.

Тикшерү барышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 26 гыйнварендә кул куелган 42 номерлы «Татарстан Республиксы бюджет чралары хисабына агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» карарына субсидияләрне бары тик банк хисабы аша гына күчерү өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Казан шәһәрендә һәм Яр Чаллы шәһәрендә **ашыгыч медицина ярдәме хезмәте (станцияләре) эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү** йомгаклары буенча бозулар 109,98 млн. сум тәшкил итә.

Мәсәлән, санитар автотранспортның гомуми бәясе 83,4 млн. сум булган Казан шәһәрендә 40 берәмлеге һәм Яр Чаллы шәһәрендә 9 берәмлеге файдаланылмый.

Бәясе 21,4 млн. сум булган төп чаралар озак вакыт кирәк булмый. Шулай, 2014 елның ноябрендә алынган 107 «Samsung» электрон планшетларының бары тик икесе генә кулланылышта.

Коррупция күренешләре куркынычы булганны күрсәтә торган фактлар ачыкланды. Запас өлешләр белән тәэмин итүгә аукционнарда аффиляцияләнгән оешмалар катнаша. Аукционнар ике катнашучы арасында үткәрелә, контрактлар иң югары бәя буенча төзелә, яисә башлангыч бәя 1%тан артыгракка кимителә. Шундый ук запас өлешләргә сатып алу бәяләре 2 тапкырдан артыкка аерылалар.

Шундый ук запас өлешләргә сатып алу бәяләре арасында шактый аерма булу җибәрелгән. Мәсәлән, «Компания Рамин Авто»да «Форд Транзит» автомобиле өчен тәгәрмәч бүкәне 2,8 мең сум бәясе белән сатып алынган булса, «ДЕПО» техник хезмәт күрсәтү станциясе ҖЧҖндә – 5,9 меңгә, ягъни 110 % ка кыйммәтрәк.

«Савой» сәүдә йорты» ҖЧҖ тарафыннан сиртмә 6,4 мең сум белән кайтарылса, «Аврора» ҖЧҖ белән төзелгән килешү буенча әлеге запас частьнең бәясе 14,6 мең сум тәшкил иткән, ягъни 128 %ка кыйммәтрәк.

2018 елның 1 апреленә торыш буенча Казан шәһәре ашыгыч медицина ярдәме станциясе балансында 128 ашыгыч ярдәм автомобиле санала, шуларның 68 е тулысынча тузган, гамәлдән төшерергә тиешле машиналар булып торалар. Шулай итеп, 60 берәмлек күләмендәге файдалану өчен яраклы булган автотранспорт чаралары белән тәэмин итү расланган күрсәткечнең 48% ын тәшкил итә.

Иң күп чакыру вакыт аралыкларында ашыгыч ярдәм килүен көтү вакытлары 10 сәгатьтән артыкка җитәргә мөмкин. Мәсәлән, Яр Чаллы шәһәрендә 2017 елда шундый чакыруларның саны 330 га җитә.

Штатлар табиблар персоналы белән 63% ка, фельдшерлар – 90%, кече медицина персоналы белән 53%ка комплектланган.

Ике эштә эшләү коэффициенты югары: табибларның – 1,6; кече медицина персоналының – 1,8 күләмендә булуы билгеләп үтелә.

Уздырылган тикшерү чаралары йомгаклары буенча Россия Федерациясе Җинаять кодексының 286 нчы «Вазыйфаи вәкаләтләрне арттыру» маддәсе буенча Казан шәһәре Ашыгыч медицина ярдәме станциясе вазыйфаи затларына карата җинаять эше кузгатылды.

2015-2017 еллар эчендә **тәмамланмаган төзелеш күләмнәрен киметү, объектларны муниципаль берәмлекләргә (файдаланучы оешмаларга) тапшыруның билгеләнгән тәртибен саклау буенча күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген тикшерү** белән 2018 елның 1 гыйнваренә карата торышка Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджеты чаралары хисабына тәмамланмаган төзелеш, реконструкция күләменең 46 458,1 млн. сум тәшкил итүен һәм өч ел эчендә 2,8 тапкыр кимүен, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты буенча –2,8 тапкыр, җирле бюджетлар буенча – 2,7 тапкыр кимүен билгеләнде.

2018 елның 1 гыйнваренә карата торышка «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» ДКУ балансында тәмамланмаган төзелеш, реконструкция составында гомуми суммасы 20 750,8 млн. сум булган 1004 объект саналган, әлеге күрсәткечнең кимүе өч ел эчендә 12 827,9 млн. сум, ягъни 61,3% тәшкил иткән, объектлар саны 1916 берәмлеккә, ягъни 190,8%ка кимегән.

«Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» ДКУ да озак вакыт финансланмый торган, файдаланучы оешмаларга тапшырылмаган аерым объектлар булуы ачыклана. Шулай, Югары Ослан муниципаль районы «Пятидворье» коттедж комплексының тәүлегенә 1000 куб метр

егәрлекле бәясе 70,8 млн. сум булган «Биологик чистарту корылмалары» объекты файдалануга тапшырылмаган һәм сакланышы тәэмин ителмәгән.

Югары Ослан муниципаль районы «Пятидворье» коттедж комплексының тәүлегенә 1000 куб метр егәрлекле биологик чистарту корылмалары

2018 елның 1 апреленә карата торышка «Татарстан Республикасы газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» ДКУ балансында финанс булмаган активларның 1078 объектына 3 897,2 млн. сумлык кертемнәр (2018 елның 1 гыйнваренә карата – 4 225,4 млн. сум, 1330 объект). санала.

Аерым объектлар буенча Газлаштыру фондының объектларны муниципаль берәмлекләргә тапшыру процедурасы тәмамланмаган, аерым техник кимчелекләр һәм башкарылган эшләрнең бәясен гомуми күләме 211,5 мең сумлык арттыру ачыкланды.

Яшел Үзән муниципаль районында үткәрелгән тикшерү гомуми күләме 291,5 млн. сум булган бозулар ачыклады, тикшерү нәтиҗәләре буенча гомуми күләме 271,1 млн. сум булган бозуларга карата (ачыкланган бозуларның 92%ы) чаралар күрелде.

Шулай, район башкарма комитеты юл эшләре үткәрү буенча кабул ителгән йөкләмәләрен үз вакытында үтәмәүләре

өчен подрядчыдан («Волгадорстрой» ААҖ) гомуми күләме 2,3 млн. сум булган штрафлар түләтү хокукыннан файдаланмаган.

Зөя авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан чаралар нәтиҗәсез файдаланылган, ул бәясе 1,5 млн. сум булган видеокүзәтү системасы сатып алуга чыгымнар тоткан. Әмма, җирлек бюджетында аны тотуга чаралар булмау сәбәпле, җиһаз файдалануга кертелмәгән.

«Мастер» балалар-яшүсмерләр спорт-техник мәктәбе картодром төзелеше өчен билгеләнгән кишәрлек өчен гомуми бәясе 2,3 млн. сум булган җир салымын түләү буенча нәтиҗәсез чыгымнар тоткан. Шул ук вакытта әлеге объект төзелеше алдагы елларда планлаштырылмаган.

Муниципаль милек белән идарә итү һәм файдалану белән бәйле бозулар 201,4 млн. сум күләмендә ачыкланган.

Гомуми бәясе 142,3 млн. сумнан артыграк булган район казнасы күчемсез милек объектларыннан (газүткәргеч, каты көнкүреш калдыкларын сортлаштыру-полигон комплексы, җылылык челтәрләре һәм башка объектлар), тиешле хокук билгеләүче документлары булмыйча, коммерциячел оешмалар («Газпромтрансгаз» ААҖ, «Зеленодольский Водоканал-сервис» ААҖ, «Экоресурс» МУП, «Яшел Үзән җылылык челтәрләре предприятиесе» ААҖ) файдалана.

Шәһәр казнасында санала торган чистарту корылмалары бинасында урнаштырылган баланс бәясе 4,5 млн. сум булган пресс-фильтр файдаланылмаган. Шулай ук Зөя авыл җирлегендә 2,3 млн. сумлык блок-модульле котельный җиһазлары 2012 елда сатып алганнан бирле эксплуатациягә кертелмәгән.

Зөя авыл җирлегендә блок-модульле котельный җиһазлары

Яшел Үзән шәһәрендә файдаланылмый торган пресс-фильтр

2015 елда район башкарма комитеты һәм Советы «Яшел Үзән шәһәренең шәһәр яшеллек хуҗалыгы» МУП нә куллануда булган алты җиңел автомобиль (Audi Q7, BMW X5, Range Rover Sport, Nissan Teana, Kia Spektra, Шевроле Нива) тапшыра, аларны соңрак аукцион аша саталар, ә сатудан килгән чараларны муниципаль учреждениенең агымдагы чыгымнарына тоталар. Әлеге операция нәтиҗәсендә район бюджетына 2,0 млн. сум акча керми.

Россия Федерациясе Җир һәм гражданлык кодекслары таләпләрен, «Конкуренцияне саклау турында» Федераль законын бозып, район Милек һәм җир мөнәсәбәтләр палатасы тарафыннан, сатулашулар уздырмыйча гына, Яшел Үзән шәһәре чикләрендә җир кишәрлеге арендалау килешүенең шартларын үзгәртә (күпфатирлы йорт төзелешеннән шәхси торак төзелешенә рөхсәт ителгән куллануның төре үзгәртелгән, арендага алынган мәйданны аерым кишәрлекләргә бүлү үткәрелгән, аренда түләве күләме үзгәртелгән). Аренда килешүендәге әлеге үзгәрешләр нәтиҗәсендә тикшерелә торган вакыт аралыгында җирле бюджет аренда өчен 2,3 млн. сум чараны алмый кала.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендә булган җирләрне максатсыз файдалануның, руда булмаган материаллар чыгара

торган карьерларны санкцияләнмәгән эшләүнең аерым очраклары ачыкланды (мисал өчен, Рус Әҗәле һәм Ильинка авыл җирлекләренең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрендә руда булмаган материаллар чыгара торган санкцияләнмәгән эшли торган ике карьер ачыкланды).

Руда булмаган материаллар чыгара торган санкцияләнмәгән карьерлар

Кама Тамагы муниципаль районында тикшерү йомгаклары буенча муниципаль милек белән идарә итү һәм файдалану өлкәсендә аерым бозулар һәм кимчелекләр ачыкланды. Гомуми баланс бәясе 49,6 млн. сум булган коммуналь инфраструктура объектлары билгеләгән тәртиптә файдалана торган оешмаларга тапшырылмаган. Башкарылган хезмәтләрнең бәясен 1,8 млн. сумга арттыру, шулай ук бухгалтерлык исәбен алып бару һәм хисап төзү тәртибен аерым бозулар да билгеләнде.



Питрәч муниципаль районында узган тикшерү барышында бер генә дәгъва кылучы булу сәбәпле, 49 җир кишәрлеген арендага бирү һәм алга таба сату, аукционнар үткәрмичә, түбәнәйтелгән бәя буенча тормышка ашыруочрагы ачыкланды. Шуның нәтиҗәсендә күрсәтелгән җир кишәрлекләрен сатудан

район бюджетына 41,9 млн. сум чамасы чара керми калган. Әлеге күренеш аренда килешүләренә иң элек арендалана торган кишәрлектә күчемсез милек объектлары төзүне тыя торган шарт булганга күрә мөмкин була. Әмма әлеге шарт соңрак күрсәтелгән кишәрлекләрне арендага бирү килешүләреннән төшерелеп калдырыла.

Шулай ук Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 маддәсен бозып, Званка авылында 0,1475 га мәйданлы җир кишәрлеге сату көненә «торак пунктлар җирләре» категориясенә күчерелгән, физик затка «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр» категориясендәге кишәрлек буларак, сатулашулар уздырмыйча, кадастр бәясе буенча сатылган.

Моннан тыш, Званка авылында «Марсель» КФХ на авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән гомуми мәйданы 163 732 кв. метр булган җир кишәрлеге елына 0,6 мең сумнан 49 елга арендага бирелгән. Тикшерү көненә әлеге кишәрлек ваграк кишәрлекләргә бүлгәләнгән, аларның бер өлешендә торак йортлар төзелә, бер өлеше 1000 кв. метры өчен 1,0 млн. сумлык бәя буенча сатуга (Интернет челтәрендәге белдерүләр буенча) куелган.

Нәкъ шулай Яңа Шигали авылы янындагы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 479 769 кв. метр мәйданлы җир кишәрлеге «Марсель» КФХ на 49 ел вакытка һәм елына 1,9 мең сум аренда түләве белән арендага бирелә. Җир шулай ук аерым кишәрлекләргә бүленгән була, анда торак йортлар төзелә. Интернет челтәрендәге белдерүләр буенча бу кишәрлекләрнең кайберләр, бәясе 1000 кв. метр өчен 0,8 млн сумнан сатуга куелган.

Биектау муниципаль районында тикшерү йомгаклары буенча муниципаль милек белән идарә итү һәм аннан файдалану белән бәйле бозулар ачыклана.

Биектау авылында җир кишәрлегеннән кала җиде бина һәм корылмадан (җитештерү базасы) торган муниципаль милек комплексын сату нәтиҗәсендә (сатып алучы – «Казан сугару техникасы заводы») җирле бюджетка 14 млн. сум чара килеп җитмәде.

Әлеге факт буенча Россия Федерациясе җинаять кодексының 286 нчы «Вазыйфаи вәкаләтләрне арттыру» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылды.

Шулай ук Россия Федерациясе Җир кодексының 8 маддәсе 11 өлешен бозып, Семиозерье авыл җирлеге территориясендә шәхси затларныкы булган һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә караган җиде җир кишәрлегенең (гомуми мәйданы 40 га һәм гомуми кадастр бәясе 304,0 мең сум) билгеләнеше үзгәртелгән.

Лаеш муниципаль районында тикшерү йомгаклары буенча бюджетны формалаштырган һәм үтәгән вакытта бозулар билгеләнгән. 2016 елда «2014-2017елларга һәм 2020 елга кадәр вакыт аралыгына авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» программасын тормышка ашыруга торак шартларын яхшыртуга гражданнарга социаль түләүләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 896,4 мең сум күләмендә кергән чаралар («Капиталь төзелеш идарәсе» МУП исәбендә тора һәм ике ел чамасы диярлек файдаланылмый, бу чараларга ихтыяҗ

булмавын һәм аларны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару зарурлыгын күрсәтә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча авыл җирендә яши торган гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту буенча 891,4 мең сум күләмендәге субсидия «2014-2017елларга һәм 2020 елга кадәр вакыт аралыгына авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» программасында катнашучыларга күчерелгән.

Гражданнарның үзара салым чараларын җәлеп итеп мәсьәләләрне чишү өчен муниципаль район бюджетына 673,8 мең сум күләмендә кергән Татарстан Республикасы бюджеты чаралары планлаштырылган нәтиҗәгә ирешелмичә файдаланылган: Урта Девятово авыл җирлегендә контрактта каралган һәм тулы күләмдә түләү башкарылган 50 куб. метр сыешлы суэтәргеч башня кую урынына 25 куб. метрлы башня куелган. Техник күзәтчелек функцияләрен «Лаеш муниципаль районы капиталь төзелеш идарәсе» МУП тормышка ашыра, 14,3 мең сум акча түләнгән. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Урта Девятово авыл җирлегендә 50 куб метр сыешлы суэтәргеч башня куелды.

Хисап палатасы ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча чаралар күрүне тикшерүгә аерым игътибар итә.

2018 елда министрлык һәм ведомстволар җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләр башлыклары адресына Хисап палатасы 43 күрсәтмә һәм 102 мәгълүмати хат юллады.

Ачыкланган барлык бозулар турында мәгълүмат һәм тиешле материаллар Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе буенча мәсьәләләр буенча ведомствоара координациләү советы

эшчәнлеге кысаларында Хисап палатасы уздырган тикшерү чаралары йомгаклары буенча мәгълүматлар квартал саен мөмкин булган җавап бирү чараларын күрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланды.

Хисап палатасы уздырган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча **бюджет чараларын тоту, республика, муниципаль милектән файдалану вакытында ачыкланган гомуми күләме 3 218,6 млн. сум** (бозуларның ачыкланган күләменнән 94%) **булган бозулар һәм кимчелекләр буенча чаралар күрелде.**

Хисап палатасы вазыйфаи затлары тарафыннан административ хокук бозулар турында 101 беркетмә төзелде.

Аларны Аксубай, Әлмәт, Буа, Биектау, Югары Ослан, Яшел Үзән, Кама Тамагы, Лаеш, Лениногорск, Питрәч һәм Тәтеш судья районнары, шулай ук Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Идел буе һәм Совет районнары, шулай Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мировой судьялары каравы нәтиҗәләре буенча 62 вазыйфаи зат һәм 2 юридик зат гомуми күләме 0,795 млн. сум булган штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура күрсәтмәләре буенча 76 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды, 6 вазыйфаи зат биләгән вазыйфаларыннан азат ителде.

Тикшерү материаллары буенча Россия Федерациясе Җинаять кодексының 286 нчы «Вазыйфаи вәкаләтләрне арттыру» маддәсе буенча 2 җинаять эше кузгатылды.

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары, тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының Европа оешмасы белән үзара хезмәттәшлек

2018 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасының Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, региональ тикшерү-хисап органнары, шулай ук тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының Европа оешмасы (алга таба – ЕВРОРАИ) белән үзара хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эше дәвам иттерелде.

Хисап вакыт аралыгында Коллегия әгъзалары, Хисап палатасы структура бүлекчәләре җитәкчеләре Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары Порталында видеоконференция форматында булып үткән бергәләп һәм параллель экспертиза-аналитик чараларга әзерлек буенча өйрәтү семинарларында катнашты. Сентябрьдә шулай ук Тышкы дәүләт аудиты (тикшерү) барышында ачыклана торган бозулар классификаторын куллануның актуаль мәсьәләләре буенча видеоконференциядә катнаштылар.

Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы комиссияләре белән аларның эш планнарында билгеләнгән юнәлешләр буенча үзара хезмәттәшлек тормышка ашырылды.

Ел дәвамында Хисап палатасы аудиторы, методология мәсьәләләре буенча комиссия рәисе урынбасары А.Р.Вәлиев һәм

Хисап палатасының юридик бүлеге җитәкчесе, хокук мәсьәләләре буенча комиссия әгъзасы С.А.Козина комиссияләр эшендә, аларның утырышларында актив катнаштылар.

Июньдә Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов һәм аудитор А.Р.Вәлиев Санкт-Петербург шәһәрендә «Иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыруда нигез буларак дәүләт финанс тикшерүе» дип аталган халыкара фәнни-гамәли форумда катнашты. Әлеге чара кысаларында Россия Финанс министрлыгы, Федераль казначылык, Монополиягә каршы федераль хезмәт, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү һәм финанс органнары, фәнни җәмәгатьчелек һәм экспертлар җәмгыятен тәкъдим иткән ике йөздән артык вәкил эчке финанс тикшерүен һәм аудитын үстерү мәсьәләләре турында фикер алышты.

Аудиториягә «Дәүләт финанс тикшерүе органнары эшчәнлегендә куркынычларны киметүгә юнәлдерелгән алым» дигән темага Хисап палатасы доклады тәкъдим ителде.

Июньдә Ульяновск шәһәрендә тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүе турында законнарны камилләштерү мәсьәләләре турында фикер алышкан регионара «түгәрәк өстәл» булды. Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советының Идел буе федераль округындагы бүлекчәсе рәисе, Татарстан Хисап палатасы Рәисе Алексей Демидов үзенең чыгышында 6-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнарын оештыру һәм эшчәнлегенең төп принциплары турында» Федераль законының

аерым нигезләмәләрен үтәү буенча республикада тышкы финанс тикшерүе органының эш тәҗрибәсе, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы уздыра торган эш турында сөйләде.

Июльдә Татарстан Республикасы Хисап палатасына Дагыстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе Б. Х. Джахбаров һәм аудитор Т.Ф. Рәсүлов килде. .

Очрашу барышында хезмәттәшләргә республика Хисап палатасындагы тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика эшчәнлегенең төп юнәлешләре, дәүләт хакимияте органнары, хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек, шулай ук Татарстанда муниципаль финанс тикшерүе системасын оештыру турында мәгълүмат бирелде.

Шулай ук Татарстан Республикасы парламентында Дагыстан Республикасы Хисап палатасы вәкилләренең Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З.Камалтынов, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы әгъзалары белән эшлекле очрашуы узды. .

Октябрьдә Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов Ялта шәһәрендә Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары җитәкчеләренең «Тышкы дәүләт финанс тикшерүе органнарының территорияләр социаль-икътисади үсешендәге роле» темасына багышланган семинар-киңәшмәсендә катнашты.

Шулай ук октябрьдә А.И.Демидов җитәкчелек иткән Татарстан Республикасы Хисап палатасы делегациясе катнашында Түбән Новгородта Россия Федерациясенең Идел

буе федераль округына керә торган субъектларының тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре өчен семинар-киңәшмә узды. Семинар «Бюджетара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дәүләт финанс тикшерүе. Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелә торган бюджетара трансфертларны куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән тикшерү һәм экспертиза-аналитика чараларын тормышка ашыру мәсьәләләре» дигән темага багышланган иде. Алексей Демидов үзенең сәламәләү чыгышында тикшерү-хисап органнары каршында тора торган иң мөһим бурычларны билгеләде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы Илнур Мөбарәков «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә бүлеп бирелгән бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеген тикшерү» дигән темага әзерләнгән доклад белән чыгыш ясады.

Декабрьдә Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы һәм Совет Президиумы утырышларында катнашты. Совет Президиумы утырышы барышында Советның Идел буе федераль округы бүлеге Рәисе, Татарстан Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов Совет бүлегенең 2018 елдагы эш нәтиҗәләре турында хисап белән чыгыш ясады.

Совет утырышында Россия Хисап палатасы Рәисе А.Л.Кудрин үз чыгышында Россия Хисап палатасының Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлеген үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә тукталды.

Алдагы елларга төп бурыч булып милли проектларның мониторингы торуы, шуңа бәйле рәвештә тикшерү-хисап органнарына тышкы аудитка стратегик якын килүне киңрәк кулланырга кирәклеге билгеләп үтелде.

Тикшерү-хисап органнарының тиешле вәкаләтләрне алуы һәм стратегик планлаштыруның тулы кыймәтле катнашучылары булсын өчен, региональ законнарны камилләштерү таләп ителә. Бергәләп эшләүнең башка юнәлешләре арасында проектлы һәм процесслы идарә кертү, цифрлы технологияләр мөмкинлекләрен киңәйтү һәм тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү билгеләп үтелде.

Хисап палатасы вәкилләре шулай ук «Милли максатларны үстерүгә ирешү мониторингы» темасына багышланган стратегик сессиядә катнашты.

Хисап вакыт аралыгында халыкара хезмәттәшлек үсеш алды. ЕВРОРАИда әгъзалык кысаларында 2018 елда Хисап палатасы вәкилләре Нидерландиядә һәм Венгриядә (апрельдә – Роттердам шәһәрендә, октябрьдә –Секешфехервар шәһәрендә) ике халыкара семинарда катнаштылар.

Венгриядә «Хакимиятнең җирле органына караган предприятиеләргә аудит» темасына багышланган семинарда Хисап палатасы аудиторы А.Р. Вәлиев докладчы һәм эшче сессияләрнең берсенең модераторы буларак чыгыш ясады.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы белән үзара хезмәттәшлек

Хисап елында Хисап палатасы муниципаль финанс тикшерүе нәтиҗәлелеген арттыруга, республика тикшерү-хисап органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшен дәвам иттерде.

Муниципаль тикшерү-хисап палаталарына оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати ярдәм күрсәтелә. Барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округларының тикшерү-хисап органнарына кураторлар – Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторлары һәм структура бүлекчәләре җитәкчеләре беркетелгән.

Ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторинг үткәрелә.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарының 12 җитәкчесе 5-7 июньдә Чиләбедә узган «Бюджет закончалыгын планлаштырылган рәвештә үзгәртеп кору юнәлешендә муниципаль тикшерү-хисап органнары вәкаләтләрен тормышка ашыру» темасына регионара түгәрәк өстәлдә, Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы әгъзаларының гомуми җыелышында катнашты.

Программа үз эченә берничә семинар-киңәшмәне алды:

- «Бюджет закончалыгы яңалыклары», «Бюджет кодексы проекты»;

- «Бюджет закончалыгын планлаштырылган рәвештә үзгәртеп кору юнәлешендә муниципаль тикшерү-хисап органнары вәкаләтләрен тормышка ашыру»;
- «Сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында законнарны куллануның актуаль мәсьәләләре», «Сатып алулар өлкәсендә аудит».

Гомуми җыелышта катнашучылар өчен шулай ук «Административ законнарны куллану практикасы. Хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек итү» һәм «Тышкы муниципаль финанс тикшерүе һәм бозуларны классификацияләүнең төп проблемалары» дип аталган дискуссион мәйданчыклар оештырылган иде.

Июньдә Хисап палатасында муниципаль тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре белән эшче киңәшмә узды. Муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре шулай ук Россия Хисап палатасының каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы оештырган өйрәтү семинарында да катнашты.

Тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләренең һөнәри үсеше максатларында Советның профильле комиссиясе дистанцияле укыту системасын кертү буенча проект әзерләде. Видеоконференция форматында узган семинар әлеге проектны тормышка ашыруның беренче этабы булды. Семинарда, законнар үзгәрүне истә тотып, гражданлык (муниципаль) хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше, дәүләт (муниципаль) хаҗәтләрне тәэмин итү өчен товарлар, хезмәтләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү һәм тышкы финанс тикшерүе органнарының административ практикасы мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

Декабрьдә булып узган Совет утырышында 2018 ел өчен эш нәтиҗәләре, тышкы финанс тикшерүенең актуаль мәсьәләләре, оештыру мәсьәләләре каралды, эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре ачыкланды, «Иң яхшы финанс тикшерүчесе» исеменә үткәрелгән бәйгегә йомгак ясалды.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек

2018 елда Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы (алга таба – Совет) эшчәнлеге кысаларында финанс тикшерүе органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеген үстерү буенча эш дәвам иттерелде. Финанс тикшерүе органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеге Тикшерү чараларының җыелма планына туры китереп тормышка ашырылды.

Финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатында, министрлыкларга, ведомство һәм республиканың муниципаль берәмлекләренә ел саен дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан ачыклана торган бозулар һәм кимчелекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә җибәрелә.

Апрельдә булган Совет утырышында дәүләт һәм муниципаль милек объектлары һәм милке белән идарә итүнең

нәтиҗәлелеген арттыру, милекне тотуга бюджет чыгымнарын оптимизацияләү буенча чаралар тикшерелде.

Совет утырышында декабрьдә карау һәм тикшерү өчен түбәндәге мәсьәләләр чыгарылды:

- бюджетка түләүләрнең тулылыгын һәм үз вакытында булуын, гомуми таралышта булган файдалы казылмаларны чыгарганда законнар таләпләрен саклауны тикшерүне көчәйтү турында;

- муниципаль берәмлекләрдә финанс тикшерүенең нәтиҗәлелеген күтәрү, җибәрелә торган бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын булдырмау буенча чаралар турында.

Хисап палатасы муниципаль районнарда уздырган тикшерү чарасы, Россия Федерациясенең башка субъектларының гомуми таралышта булган файдалы казылмаларны чыгару мәсьәләләрен регламентлау өлешендә алдынгы тәҗрибәсен өйрәнү йомгаклары буенча әлеге өлкәдә бозуларны кисәтү буенча тәкъдимнәр комплексы әзерләнде.

Муниципаль берәмлекләрдә финанс тикшерүенең нәтиҗәлелеген күтәрү, җибәрелә торган бозуларның сәбәпләре һәм шартлары мөмкинлегенә юл куймау буенча чаралар турында мәсьәлә хакында фикер алышу нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләр башлыклары адресына, тикшерү-хисап палаталары функционалын җәлеп итеп, бюджет дисциплинасы дәрәҗәсен күтәрү буенча тәкъдим ителә торган чаралар белән мөрәҗәгать юлланды.

Майда Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору буенча эшне көйләү Комиссиясенең «2017 елда коррупциягә каршы тору буенча эш һәм аларның сәбәпләрен һәм шартларын юкка чгару һәм 2018 елга бурычлар турында» көн тәртибе белән узган утырышында өстәмә доклад белән чыгыш ясады. Өстәмә докладта эшчәнлекнең элеккечә үк югары коррупция зонасында кала торган проблемалы өлкәләреннән конкрет мисаллар китерелде: аерым муниципаль районнарда җир кишәрлекләренең шактый өлеше сатулашулар уздырмыйча гына арендага бирелгән һәм сатылган; дәүләт һәм муниципаль сатып алулар өлкәсендә бюджет чаралары хисабына сатып алынган җиһазларның озак вакытлар файдаланылмау фактлары ачыкланды; мәгариф учреждениеләрендә бер үк исемдәге туклану продуктларына сатып алу бәяләрендә шактый аерма булуы ачыкланды. Коррупциягә каршы чаралар контекстында шулай ук игътибар сорый торган тагын бер аспект билгеләп үтелде – бу коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш оештыру.

Казан (Идел буе) федераль университетының Югары дәүләт һәм муниципаль хезмәт мәктәбе белән хезмәттәшлек кысаларында 2018 елда Хисап палатасы вәкилләре квалификация күтәрү курслары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри әзерлек программаларын уздыруда катнашты.

Майда Россия Хөкүмәте каршындагы «Study-tour 2018 – Россия Федерациясендә региональ идарә тәҗрибәсе» Финанс университеты «Дәүләт һәм муниципаль идарә» кафедрасының күчмә инновацияле мәгариф проектында катнашучылар Хисап палатасында булып китте. Студентлар һәм вәкилләр төркеме

Татарстан Республикасы тышкы дәүләт финанс тикшерү органы эшчәнлегенең төп юнәлешләре белән танышты.

Эшчәнлектә хәбәрдарлык

2018 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасы Коллегиясе, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү Советы һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары массакүләм матбугат чараларында даими рәвештә яктыртылып торды.

Хисап вакыт аралыгында массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет басмалар, журналлар, газета һәм телевидение) Хисап палатасы эшчәнлеге 406 материалда, шул исәптән федераль һәм региональ басмаларда: РИА-Новости, «РБК», «РЕГНУМ», «Татар-информ», «Волга-информ» (Самара), «Мангазея» (Петропавловск-Камчатский) мәгълүмат агентлыкларының веб-сайтларында, «БизнесOnline» һәм «Реальное время» электрон газеталарында, «Без Формата» (Санкт-Петербург), «Chel.Pro» (Челябинск), «Красноярские новости», «РыбинскOnline», «Твой город Псков», «Idel.Реалии» веб-сайтларында, Yandex/новости, Mail.ru-новости, Rambler.новости, «Медвестник.ru» интернет-порталларында; «Аргументы и Факты», «Аргументы недели», «Комсомольская правда», «Известия», «МК» газеталарының региональ чыгарылышларында, НТВ телеканалында тәкъдим ителде.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.tatar), Россия Федерациясе Хисап

палатасы һәм Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары порталында (http://www.portalkso.ru) урнаштырылды.

2018 елда Хисап палатасы сайтына 26 730 тапкыр керү теркәлгән.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге хроникасы квартал саен Татарстан Республикасы Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнәрендә басылып чыкты. Бюллетеньнар Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.